# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

2023 елның 5 октябре №152

Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы карарларының үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль хокукый актлар системасын актуальләштерү максатыннан, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Ачасыр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Олы Ачасыр авыл җирлеге Советының 2016 елның 14 апрелендәге 52 номерлы «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм аларга ия булуны, акчаларны һәм кыйммәтле әйберләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында»гы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

Олы Ачасыр авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе И.М. Саттаров